# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге составына керүче Яңавыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

2024 нче елның 8 нче апреле № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 22 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Айбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге Советының 23.10.2019 елның 162 № лы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә» буенча 2024 нче елның 5 нче апрелендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Яңавыл торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Яңавыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 25.10.2023 ел, № 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: "2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Яңавыл торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)
- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу)
- урам яктыртуны ремонтлау

2023 елның 25 октябрендәге 2 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен шул өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)
- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу)
- урам яктырту җайланмасы (урам яктыртуны ремонтлау)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 87 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 55 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленә: «Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 55 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Шуның нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге составына керүче Яңавыл торак пунктында гражданнар җыены узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре чын дип санарга.

2. «Сез Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Яңавыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 25.10.2023 ел, № 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: "2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Яңавыл торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- авыл эчендәге юлларны һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу)

- урам яктыртуны ремонтлау

2023 елның 25 октябрендәге 2 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен шул өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, кышкы юлларны карап тоту)

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу)

- урам яктырту җайланмасы (урам яктыртуны ремонтлау)

«РИЗА» «КАРШЫ» -

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Айбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин